Татар мәктәбендә укучы балаларга
татар теленнән мәктәп олимпиадасы өчен биремнәр
7 нче сыйныф
2016-2017 уку елы

**Үткәрү вакыты – 90 минут**
**Максималь балл –** ***64 балл***

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Хәрефләргә караганда авазлар саны күбрәк булган сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) яшьлек;

ә) көньяк;

б) бияләй;

в) кульъяулык.

2. **һ** хәрефе языла торган сүзләр рәтен билгеләгез. ***(2 балл)***

а) ..ади, Ил..ам, ..өнәр, зин..ар;

ә) ..әтер, тари.. , ..ата, пө..тә;

б) ..езмәт, ..ыял, ..айван, ..ат;

в) ..әйдәр, ..әлил, ..әлим, ..алык.

3. Алфавит тәртибендә язылгансүзләр рәтенбилгеләгез. ***(2 балл)***

а) Әмир, Булат, Җәмилә, Тимерхан;

ә) ашъяулык, сандугач, калай, токмач;

б) итәк, җил, һава, савыт;

в) юлдаш, ташчы, шәл, Гөлнара.

4. Диалекталь сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) сингармонизм, иҗек, антоним, басым;

ә) витамин, гимн, фонтан, макарон;

б) айбагар, ызба, әпәй, кәй;

в) бәрәңге, тапкырлау, җиләк, егет.

5. Фразеологик әйтелмәгә туры килгән сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***

***Күз ачып йомганчы.***

а) елау;

ә) качу;

б) шатлану;

в) бик тиз.

6. Калын хәрефләр белән бирелгән исемгә дөрес морфологик анализ ясалган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

*Чәчәкнең* ***матурлыгы*** *берни түгел, хуш исе булмаса.* (Мәкаль)

а) уртаклык исем, тамыр, берлек санда, баш килештә, тартым белән төрләнгән;

ә) уртаклык исем, тамыр, күплек санда, баш килештә, тартым белән төрләнмәгән;

б) ялгызлык исем, кушма, берлек санда, баш килештә, тартым белән төрләнгән;

в) уртаклык исем, тамыр, берлек санда, юнәлеш килешендә, тартым белән төрләнгән.

7. Җыю саны кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Җиде кат үлчә, бер кат кис. (Мәкаль);

ә) Биш юләргә киңәш иткәнче, бер акыллыга киңәш ит. (Мәкаль);

б) Икәү булсаң, береңә киңәш ит, берәү булсаң, бүрегеңә киңәш ит. (Мәкаль);

в) Үзеңнән бер яшь өлкәннән акыл сора. (Мәкаль).

8. Калын хәрефләр белән бирелгән рәвешкә дөрес морфологик анализ ясалган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

*Беренче сентябрьдә күк күкрәсә, киләсе ел ашлык уңар, ләкин көз* ***озак*** *килер*. (Сынамыш)

а) саф рәвеш, кушма, төп дәрәҗәдә, *килер* фигыленә ияргән;

ә) вакыт рәвеше, тамыр, төп дәрәҗәдә, *килер* фигыленә ияргән;

б) күләм-чама рәвеше, тамыр, төп дәрәҗәдә, *көз* исеменә ияргән;

в) күләм-чама рәвеше, тамыр, төп дәрәҗәдә, *килер* фигыленә ияргән.

9. Нисби сыйфатлардан гына торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) кыю, яшь, батыр, ак;

ә) күктәге, кышкы, яшел, чибәр;

б) өйдәге, фәнни, көндәлек, тарихи;

в) йомшак, көрән, рәхәт, кулындагы.

10. Мәкальдәге хәл фигыльләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

*Песи сөтне күз йомып ашагач, үзен беркем дә күрми дип уйлый.* (Мәкаль)

а) йомып, ашагач;

ә) йомып, ашагач, күрми;

б) йомып, ашагач, күрми, дип;

в) йомып, ашагач, күрми, уйлый.

11.Тиңдәш аергычлар кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Зәңгәр һавада зур кызыл шар оча.

ә) Безнең сыйныфта белемле һәм акыллы кызлар укый.

б) Әнием кибеттән тәмле йомшак күмәч алып кайтты.

в) Мин китапларны һәм дәфтәрләрне өстәл тартмасына салдым.

12. Кушма җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Һәркем үзен генә түгел, якыннарын да кайгыртырга тиеш.

ә) Алсу, Гөлназ һәм Марат кибеткә киттеләр.

б) Кар ява, ләкин балалар урамнан кермиләр.

в) Мин язам, укыйм һәм сөйлим.

## II. Теоретик бирем.

Теркәгечләр турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. ***(10 балл)***

## III. Грамматик һәм иҗади бирем.

Сүзләргә сузык авазлар өстәп, мәкальне языгыз, түбәндә бирелгән грамматик һәм иҗади биремнәрне үтәгез.

БР ЙХШ Ш МҢ ЙХШ СЗДН РТК. ***(7 балл)***

1. Мәкальдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. ***(7 балл)***
2. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз. ***(7 балл)***
3. Соңгы сүзгә фонетик анализ ясагыз. ***(4 балл)***
4. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. ***(5 балл)***